**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

2019 елның 21 февраленнән №7-РС

**КАРАР**

**“Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

2003 елның 6 октябреннән № 131-ФЗ “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы һәм 2005 елның 21 июленнән №97 “Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында”гы Федераль законнарга, 2004 елның 28 июленнән №45-ЗРТ “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы Татарстан Республикасы Законына ярашлы төстә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль район Советы **КАРАР БИРӘ:**

1. “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына кушымтага ярашлы төстә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Бу карарны законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә юлларга.
3. Әлеге карарның, гамәлдәге закон белән башкалар билгеләнгән булмаганда, 2003 елның 6 октябреннән № 131-ФЗ “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 44 маддәсе, 8 бүлегенә һәм “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставының 91 маддәсе, 2 бүлегенә ярашлы төстә үз көченә керәчәген билгеләргә.
4. Бу карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы һәм Лаеш муниципаль районы рәсми сайтының Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырырга (халыкка чыгарырга).
5. Әлеге карар үтәлешенә контрольлек итүне район Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек итү буенча комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык – муниципаль район Советы рәисе** **М.П. Афанасьев**